| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2016_____ г. Казань № под-1247/16

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 18 ноябрендәге 6575/14 номерлы боерыгы белән расланган Ятим балаларны һәм эти-әни тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм эти-әни тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан яшәү урыны алуга мохтаҗлар сыйфатында исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 22 июнендәге 1247/16 номерлы боерыгы

«Инвалидлар турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә ивалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419 номерлы федераль законның 26 статьясының 4 өлешендәге 2 пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 18 ноябрендәге 6575/14 номерлы боерыгы белән (Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 4 сентябрендәге 9242/15 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Ятим балаларны һәм эти-әни тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм эти-әни тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан яшәү урыны алуга мохтаҗлар сыйфатында исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 22 июнендәге 1247/16 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.4 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итәргә кирәклеген исәпкә алып, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты, әгәр туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса»;

Таблицаның «Стардартка карата таләп эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле икенче абзац белән тулыландырырга:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.»;

2.5 пунктта таблицаның «Стандартка карата таләп эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу өчен, гариза бланкын Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан, түбәндәге ысулларның берсен кулланып, кәгазьдә тапшырыла (юллана) ала:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменән эш итүче зат тарафыннан);

тапшыру турында хәбәр итү юлы белән почта аша заказ ясап җибәрү.

Шулай ук гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Дәүләт хезмәтләренең һәм муницпаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша тапшырыла (юллана) ала.»;

2.6 пунктта таблицаның «Стандартка карата таләп эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Документларны алу ысуллары һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны бирү тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган түбәндә саналган документларны таләп итү тыела.»;

2.14 пунктта:

таблицаның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү һәм гариза тапшыручыларны кабул итү урынына, шул исәптән, күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законы нигезендә, ачыклыкны тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм бизәүгә таләпләр»;

таблицаның «Стандартка карата таләп эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына инвалидларның тоткарлыксыз үтүе, шул исәптән, объектка тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук, дәүләт

хезмәтен күрсәтү урынына бару максатыннан, объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәтен күрстәү тәртибе турында визуаль, тест һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен, шул исәптән, инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәкә алып, уңайлы урыннарда урнаштырыла.»;

2.15 пунктта:

таблицаның «Стардартка карата таләп эчтәлеге» графасын түбәндәге редакцядә бирергә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең ачыклык күрсәткече булып тора:

бүлек урыны җәмәгатьчелек транспорты йөргән зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар алына торган урыннарның кирәкле санда булуы;

мәгълүмат такталарында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакыты турында мәгълүмат булуы;

законда каралганча, инвалидлар өчен үтеп йөрү шартлары булу.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:

документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә биргәндә, чиратлар;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын бозу;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләренең эш-гамәлләренә (битарафлыкларына) шикаятьләр;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләренең гариза бирүчеләргә нәзакәтсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.

Гариза бирүченең, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, Министрлык белгечләре белән турыдан-туры сөйләшүләр саны – бердән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша юллаганда – бердән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә гариза бирүче барлык кирәкле документларны тиешле тәртиптә раслаган рәвештә тапшырса, сөйләшүләрнең кирәге калмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Гариза бирүче белән сөйләшү вакыты – 15 минуттан артмый.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читләштерелгән эш урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтелми, шул исәптән, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гаризалар бирелми.

Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат mon.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә алынырга мөмкин.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Л.О. Сулимага йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры - министр Э.Н. Фәттахов

ТР Юстиция министрлыгында 2016 елның 18 июлендә теркәлде.
Теркәлү номеры 3428